ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

24 июль **2024 ел** **№** 82

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында халык күп җыела торган урыннарны билгеләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

«Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле халык күп җыела торган урыннарны һәм объектларны (территорияләрне) террорчылыктан саклауга һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлек паспортлары формаларына карата таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 апрелендәге 272 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, халык күп җыела торган урыннарның террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән көчләрне берләштерү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

- халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә;

- Арча муниципаль районы территориясендә халык күп җыела торган урыннар исемлеген 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М. Гатиятовка йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ
ИНН 1609009523

Арча муниципаль
районы башлыгының
«24» июль 2024 ел, № 82
карарына 1 нче кушымта

**Халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) даими эшләүче координацияләү органы булып тора, аның эшчәнлеге кешеләр күп җыела торган урыннарны категорияләргә бүлүгә юнәлдерелә.

2. Комиссияне төзүнең максаты

Комиссияне төзүнең максаты - халык күп җыела торган урыннарда террорчылык актлары кылыну куркынычы һәм мөмкин булган нәтиҗәләрен исәпкә алып, аларның иминлеген тәэмин итүгә дифференциацияләнгән таләпләр билгеләү өчен халык күп җыела торган урыннарны категорияләргә бүлүне оештыру.

3. Комиссиянең вәкаләтләре

Комиссия түбәндәеләргә хокуклы:
3.1. Халык күп җыела торган урыннарны тикшерү һәм категорияләргә бүлү үткәрергә.
3.2. Халык күп җыела торган урыннарны тикшерү һәм категорияләргә бүлү актларын төзергә.
3.3. Халык күп җыела торган урыннарның террорчылыктан саклануын тәэмин итү чараларын билгеләргә.
3.4. Халык күп җыела торган урыннарның террорчылыктан саклануына карата таләпләр үтәлешен планлы һәм планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырга.

4. Комиссиянең эш тәртибе

4.1. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.
4.2. Комиссияне Комиссия рәисе җитәкли. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.
4.3. Комиссия рәисе:
а) Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Көн тәртибен билгели. Аның утырышларында мәсьәләләрне карау сроклары һәм тәртибен билгели;
б) Комиссия утырышларын уздыру инициативасы белән чыга;
в) Комиссия утырышы эшен алып бара;
г) халык күп җыела торган урыннарны тикшерү һәм категорияләргә бүлү актларына һәм Комиссия вәкаләтләрен үтәүгә кагылышлы башка документларга кул куя.
4.4. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:
а) халык күп җыела торган урынның милекчесе яисә кешеләрнең массакүләм булу урыныннан башка законлы нигездә файдаланучы зат;
б) территориаль иминлек органы вәкилләре;
в) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре,

*Арча муниципаль*
*районы башлыгының*
*«24» июль 2024 ел, № 82*
*карарына 2 нче кушымта*

**Халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Ренат Мансурович | – Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе (килешү буенча); |
| Халиков Айдар Фатыйхович | – Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Арча районы буенча кураторы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча). |

***Комиссия әгъзалары :***

| | |
|---|---|
| Баһавиев Айдар Рашатович | – Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Гыйльмуллин Раил Гомәрович | – Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Арча һәм Әтнә муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Касыймов Рөстәм Фәридович | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Халык күп җыела торган урыны милекчесе яисә халык массакүләм җыелу урыныннан башка закон нигезендә) файдаланучы зат (килешү буенча); |
| Фәйзрахманов Рамил Рәшидович | – Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге – "Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе" Федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы башлыгы (килешү буенча); |
| Юзаев Искәндәр Илнарович | – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Янгынга каршы федераль хезмәтенең 7 нче янгын-коткару отрядының 107 нче янгын-коткару части башлыгы; |
| Зәйнуллин Илназ Минсурович | – Арча муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе |

гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының территориаль органнары вәкилләре.

Кирәк булганда, Комиссия эшенә халык күп җыела торган урын чикләрендә яки аңа турыдан-туры якын урында урнашкан объектларның милекчеләре вәкилләре җәлеп ителә.

4.5. Комиссия эшенең нәтиҗәләре халык күп җыела торган урынны тикшерү һәм категорияләргә бүлү акты белән рәсмиләштерелә, ул 6 нөсхәдә төзелә, Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм халык күп җыела торган урынның иминлек паспортының аерылгысыз өлеше булып тора.

4.6. Халык күп җыела торган һәр урынга, аны тикшергәннән һәм категорияләргә бүлгәннән соң, Комиссия тарафыннан иминлек паспорты төзелә. Иминлек паспорты 6 нөсхәдә төзелә, ул территориаль иминлек органнары, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы җитәкчеләре белән килештерелә һәм Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

*Арча муниципаль*
*районы башлыгының*
*«24» июль 2024 ел, № 82*
*карарына 3 нче кушымта*

**Арча муниципаль районы территориясендә халык күп җыела торган урыннар исемлеге**

| № | Объектның исеме | Урнашкан урыны |
|---|---|---|
| 1 | «Казан Су» паркы | ТР, Арча районы, Арча шәһәре, Подгорная урамы |